# БРОНТЕ КЭМПБЕЛЛ – ИРЕКЛЕ СТИЛЬ БЕЛӘН 50 МЕТРГА ЙӨЗҮДӘ ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНКАСЫ

09.08.2015, 18:35
СПОРТ

**Бу минутларда су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионатының соңгы ярыш көненең дүртенче финал йөзеше тәмамланды. Ирекле стиль белән 50 метр арага ярышта дөньяның иң җитез 8 йөзүче кызы ярышты.**

Ирекле стиль белән 50 метрга йөзү ярышында австралияле Бронте Кэмпбелл Дөнья чемпионкасы булды. Ул бу араны 24.12 секундта йөзеп узды. Икенче нәтиҗәне голландияле Раноми Кромовидьойо күрсәтте, аның нәтиҗәсе - 24.22 секунд. Призлы өчлекне, 23.31секундлы нәтиҗә белән, Швеция кызы Сара Шестрем япты.

ДЧ-2015.Йөзү.

Хатын-кызлар. Ирекле стиль, 50 м.

1. Бронте Кэмпбелл (Австралия) – 24.12

2. Раноми Кромовидьойо (Нидерланд) – 24.22

3. Сара Шестрем (Швеция) – 24.31

9 август. Казан. “Казан Арена”

Су спорт төрләре буенча 16 нчы дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА